**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4863**
**25.09.2019**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында

Бюджет кодексының 47.2 маддәсенең 4 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 нче карары белән расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карарларны кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 нчы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезнамәнең 7.1 маддәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен, 1 нче кушымтада каралганча;

2) активлар керү һәм чыгу буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибе турындагы нигезнамәне раслау турында» 2017 елның 6 апрелендәге 1957 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А.Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р. Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 25 сентябрендәге
4863 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип Бюджет кодексының 47.2 маддәсенең 4 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 нче карары белән расланган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карарларны кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы 26/6 нчы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезнамәнең 7.1 маддәсе нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты (алга таба – шәһәр бюджеты) алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча гражданнарның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм юридик затларның бурычын исәптән чыгару кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

2. Әлеге тәртип салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда, производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәргә бәйле авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү турында Россия Федерациясе законнарында, Евразия икътисадый берлеге хокукында һәм таможня эше турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән түләүләргә, гавами-хокукый берәмлек алдындагы акчалата йөкләмәләргә кагылмый.

3. Шәһәр бюджетына билгеләнгән срокка түләнмәгән түләүләр (шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурыч) түбәндәге очракта түләтүгә өметсез дип танылa:

1) физик зат – шәһәр бюджетына түләүләр түләүче вафат булганда яки Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә аны үлгән дип игълан ителгәндә;

2) шәхси эшмәкәр – шәһәр бюджетына түләүләр түләүче «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, бурычлы затның мөлкәте җитмәү сәбәпле, шәһәр бюджетына түләүләр буенча түләнмәгән бурычлары өлешендә банкрот дип танылганда;

3) оешма милке җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан аларны түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле, шәһәр бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурычлар өлешендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә оешма – шәһәр бюджетына түләүче бетерелгәндә;

4) бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва бирү срогы) чыгу, шул исәптән шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза бирүнең югалган срогын кире кайтарудан баш тарту турында суд тарафыннан билгеләмә чыгарылу сәбәпле, бюджет керемнәре администраторының шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында суд тарафыннан акт кабул ителгәндә;

5) суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ санлы Федераль законның 46 маддәсе 1 бүлегенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкару производствосының тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, бюджетка түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан биш елдан күбрәк вакыт узган булса түбәндәге очракларда:

- бурыч күләме, бөлгенлеккә төшү турындагы эш буенча производство кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында Россия Федерациясе законында бурычлыга карата билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

- шәһәр бюджетына түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалары булмау сәбәпле банкротлык турында эш производствосы туктатылганда.

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган очраклардан тыш, билгеләнгән срокта түләнмәгән административ штрафлар, мондый срокны өзү, туктату яки озайту өчен нигезләр булмаганда, административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүнең Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән срогы чыккан очракта, түләтүгә өметсез дип таныла.

5. Шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигезләрнең булуын раслаучы документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) инвентаризация нәтиҗәләре турында акт (Россия Финанс министрлыгының «Дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кулланыла торган беренчел исәп документлары һәм бухгалтерлык исәбе регистрлары формаларын һәм аларны куллану буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2015 елның 30 мартындагы 52н санлы Приказы (алга таба – Россия Финанс министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 52н санлы Приказы) белән расланган ф. 0504835);

2) керемнәр буенча исәп-хисапларның инвентаризация исемлеге (Россия Финанс министрлыгының 2015 елның 30 мартындагы 52н санлы Приказы белән расланган ф. 0504091);

3) әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча, керемнәр администраторы хисапларыннан шәһәр бюджетына түләүләр буенча исәпкә алынган бурыч суммасы турында өземтә;

4) керемнәр администраторыннан шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында белешмә;

5) шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар:

- физик затның – шәһәр бюджетына түләүләрне түләүченең үлемен таныклый яки аны үлгән дип белдерү фактын раслый торган документ;

- шәхси эшмәкәрнең – шәһәр бюджетына түләүләр түләүченең банкрот дип танылуы нәтиҗәсендә эшчәнлеге тукталу турында Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан, оешманың – шәһәр бюджетына түләүләрне түләүченең бетерелү сәбәпле эшчәнлеге тукталу турында Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматларны үз эченә алган документ;

- бурычны түләтүнең билгеләнгән срогы (дәгъва бирү срогы) чыгу, шул исәптән шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү турында судка гариза бирүнең югалган срогын кире кайтарудан баш тарту турында суд билгеләмәсе чыгарылу сәбәпле, бюджет керемнәре администраторының шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында суд акты;

- суд приставы-башкаручының «Башкару производствосы турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ санлы Федераль законның 46 маддәсе 1 бүлегенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча, түләтүчегә башкару документы кире кайтарылган очракта, башкару производствосының тәмамлануы турында карары.

## 2 бүлек. Шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе

6. Шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану инициаторы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең идарә ителә торган керемнәр буенча беренчел документларның тулылыгын һәм бюджет исәбендә үз вакытында чагылдырылуын тәэмин итү бурычлары йөкләнгән Башкарма комитетның тиешле тармак органы (алга таба – Башкарма комитетның тармак органы) тора.

7. Башкарма комитетның тармак органы агымдагы елның 1 декабренә кадәр еллык бюджет хисаплылыгын төзер алдыннан йөкләмәләргә инвентаризация үткәрә.

8. Әлеге тәртипнең 3 пунктында каралган билгеләре булган бурыч ачыкланганда, инвентаризация үткәрү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитетның тармак органы инвентаризация нәтиҗәләрен рәсмиләштергән вакыттан башлап 5 эш көне эчендә әлеге тәртипнең 5 пунктында каралган документларны активлар керү һәм чыгу буенча комиссиягә (алга таба – комиссия) җибәрә.

9. Комиссия эшчәнлегенең максаты булып, шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны алга таба исәптән чыгару өчен, аны түләтүгә өметсез дип тану тора.

10. Комиссия эшчәнлегенең бурычы булып Башкарма комитетның тармак органы тарафыннан тапшырылган документларны карап тикшерү тора.

11. Комиссия әгъзалары саны биш кешедән ким булмаган так санда булырга тиеш. Комиссия составы Башкарма комитет карары белән раслана.

12. Комиссия рәистән, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия эшчәнлегенә – рәис, ул булмаганда рәис урынбасары җитәкчелек итә. Комиссия секретаре булып Башкарма комитетның тармак органы вәкиле тора.

13.Комиссия әгъзалары:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашалар;

2) комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертәләр;

3) комиссиядә карап тикшерүгә чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашалар;

4) карап тикшерүгә чыгарылган мәсьәлә буенча фикер әйтәләр;

5) шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы актны имзалыйлар.

14. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиягә документлар кергән көннән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча, утырыш үткәрү датасын билгели;

2) комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

3) шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы актны имзалый.

15. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара.

16. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиянең эшен алып бара;

2) комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;

3) комиссия утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында комиссия әгъзаларына хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмати материаллар белән тәэмин итә;

4) әлеге тәртипкә 2 нче кушымтада каралганча, шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында акт әзерли.

17. Комиссия эшчәнлегенең формасы булып утырыш тора. Комиссия утырышлары Башкарма комитетның тармак органыннан әлеге тәртипнең 5 пунктында каралган документлар кергән саен уздырыла.

18. Комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

19. Шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында комиссия карары утырыш үткәрелгән көнне түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

1) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме);

2) салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, оешманың салым түләүчесен исәпкә кую сәбәбенең коды (физик зат салым түләүченең идентификация номеры);

3) бурыч барлыкка килгән түләү турында мәгълүматлар;

4) шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурыч, исәпкә алына торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәренең классификация коды, аның исеме;

5) шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы;

6) шәһәр бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар

буенча бурыч суммасы;

7) шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү датасы;

8) комиссия әгъзаларының имзалары.

20. Комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы акт, имзаланган вакыттан башлап ике эш көне эчендә, раслау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелә.

21. Башкарма комитет Җитәкчесе шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы акт кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә аны «Раслыйм» грифына виза салу юлы белән раслый.

22. Шәһәр бюджетына түләүләр буенча түләтүгә өметсез бурычны исәптән чыгару, ул расланган көннән башлап биш эш көне эчендә шәһәр бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы акт нигезендә Башкарма комитет Финанс идарәсенең исәп һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

23. Башкарма комитетның тармак органы, әлеге тәртипкә 3 нче кушымтада каралганча, салым булмаган керемнәрнең төрләре буенча шәһәр бюджетына түләүләр буенча исәптән чыгарылган бурыч реестрын алып бара.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 25 сентябрендәге
4863 нче карары белән расланган
Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге бюджетына түләүләр
буенча бурычны
түләтүгә өметсез дип тану турында
карар кабул итү тәртибенә
1 нче кушымта

____________________________ ел буенча
______________________________________________
(оешманың исеме (ИНН/КПП),
физик затның Ф.И.А.и. (ИНН булганда)
___________________________________________________ муниципаль берәмлеге
бюджетына түләүләр түләү буенча исәпкә алына торган бурыч суммалары турында
_____________________________________ хисаплылыгынннан
(керемнәр администраторы)

ӨЗЕМТӘ

(сум)

| Т/с | Түләү төре | Түләүне түләү буенча бурыч барлыкка килү вакыты | Түләүне түләү буенча барлык бурыч | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Төп бурыч | Пенялар | Штраф лар |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | |

Башкарма комитетның
тармак органы җитәкчесе ______________ (Ф.И.А.и.)
(имза)
М.У.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 25 сентябрендәге
4863 нче карары белән расланган
Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге бюджетына түләүләр
буенча бурычны
түләтүгә өметсез дип тану турында
карар кабул итү тәртибенә
2 нче кушымта

РАСЛЫЙМ
Башкарма комитет
Җитәкчесе
_________________________________
(шәхси имзасы, имзаның расшифровкасы – Ф.И.А.и.)
«_____» ______________ 20___ел

Бюджетка түләүләр буенча бурычны
түләтүгә өметсез дип тану турында
АКТ

«_____» ______________ 20___ел №_____

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
(оешманың тулы исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________________________________
(оешма өчен ИНН, ОГРН, КПП, физик зат өчен ИНН)

| | |
|---|---|
| Бурыч барлыкка килгән түләү турында мәгълүматлар | |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәренең классификация коды, аның исеме | |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы | |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы | |

_______________________________________________________________________________
(реквизитлары белән конкрет документлар күрсәтелә)

_____________________________________________________nигезендә бурычны

түләтүгә өметсез дип таныргә.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Комиссия рәисе | ______________<br>(вазыйфасы) | ______________<br>(имзасы) | (Ф.И.А.и..) |
| | | М.У. | |
| Комиссия әгъзалары: | | | |
| | ______________<br>(вазыйфасы) | ______________<br>(имзасы) | (Ф.И.А.и..) |
| | | М.П. | |
| | ______________<br>(вазыйфасы) | ______________<br>(имзасы) | (Ф.И.А.и..) |
| | | М.У. | |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2019 елның 25 сентябрендәге
4863 нче карары белән расланган
Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
бюджетына түләүләр буенча бурычны
түләтүгә өметсез дип тану турында
карар кабул итү тәртибенә
3 нче кушымта

______________________________________________________
(керемнәр администраторы)
__________ел өчен
салым булмаган керем төрләре буенча ________________________________________ муниципаль берәмлеге бюджетына
түләүләр буенча исәптән чыгарылган бурыч
РЕЕСТРЫ

(руб.)

| Т/с | Бурычны өметсез дип тану нигезе | Оешманың исеме (ИНН/КПП), физик затның Ф.И.А.и. (ИНН булганда) | Түләүнең төре | Түләүне түләү буенча бурыч барлыкка килү вакыты | Исәптән чыгарылган бурыч суммасы, барлыгы | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Төп бурыч | Пенялар | Штрафлар |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | |

Башкарма комитетның
тармак органы җитәкчесе ______________ (Ф.И.А.и.)
(имзасы)

М.У.

Башкарма комитетның
2019 елның 25 сентябрендәге
4863 нче карарына
2 нче кушымта

Активлар керү һәм чыгу буенча комиссия
составы

| Вазыйфаи затның Ф.И.А.и. | вазыйфасы |
|---|---|
| Сәгыйдуллина<br>Ирина Алексеевна | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | |
| Фәхретдинова<br>Светлана Зиннур кызы | Башкарма комитетның бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Хәмидуллина<br>Гүзәл Рәшит кызы | Башкарма комитет финанс идарәсенең хисап һәм хисаплылык бүлеге башлыгы |
| Гыйльванова<br>Айгөл Владимировна | Башкарма комитетның бухгалтерлык хисабы һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары, бүлек башлыгы |
| Башкарма комитетның тармак органы вәкиле | комиссия секретаре |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова